КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 октябрь г.Казань № 891

БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын үткәрү көннәрендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын үткәргәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 22 октябреннән 24 октябренә кадәр БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын үткәрү көннәрендә кушымта нигезендә БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын үткәргәндә җәлеп ителгән территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сату (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш) тыела.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм, килештереп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 октябрь, 891 нче
карарына кушымта

БРИКС илләре башлыклары очрашуын үткәргәндә җәлеп ителгән территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларының урнашу урыны

| Т/с | БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын үткәргәндә җәлеп ителгән территориядә урнашкан объект адресы | Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган сәүдә объекты адресы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы, Казан ш., Николай Ершов ур., 1 нче А й. | Казан ш., Николай Ершов ур., 1 нче А й. |
| 2. | 5* «Kazan Palace by TASIGO» отеле, Казан ш., Калинин ур., 3 нче Б й. | Казан ш., Волков ур., 48/22 нче й. |
| 3. | 4* «NEO Kazan Palace by TASIGO», Казан ш., Калинин ур., 3 нче В й. | Казан ш., Волков ур., 48/22 нче й. |
| 4. | «Шаляпин Палас Отель» кунакханәсе, Казан ш., Университет ур., 7/80 нче й. | Казан ш., Бауман ур., 82 нче й. |
| 5. | 4* «RELITA-KAZAN» отеле, Казан ш., Декабристлар ур., 85 нче Г й. | Казан ш., Декабристлар ур., 85, 88 нче йортлар; Ибраһимов проспекты, 56 нчы й. |
| 6. | 4* «Хаял» отеле, Казан ш., Университет ур., 16 нчы й. | Казан ш., Университет ур., 20 нче й.; Пушкин ур., 19 нчы й. |
| 7. | «Cosmos Kazan Hotel» кунакханәсе, Казан ш., Лесгафт ур., 7 нче й. | Казан ш., Лесгафт ур., 6/57 нче й. |
| 8. | «DoubleTree by Hilton Kazan City Center» кунакханәсе, Казан ш., Чернышевский ур., 21 нче й. | Казан ш., Сулъяк Болак ур., 24/20 нче й. |
| 9. | «Отель Арт» кунакханәсе, Казан ш., Островский ур., 33 нче й. | Казан ш., Островский ур., 31 нче й.; Университет ур., 4/34 нче й. |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | «Рамада Казань Сити Центр» («Ramada by Wyndham Kazan City Centre»), Казан ш., Чернышевский ур., 39 нчы й. | Казан ш., Чернышевский ур., 37 нче й. |
| 11. | Казан Ратушасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 33 нче й. | Казан ш., Зур Кызыл ур., 29 нчы й. |
| 12. | «Гранд отель Казань» отеле, Казан ш., Петербург ур., 1 нче й. | Казан ш., Петербург ур., 1 нче й. |
| 13. | «LUCIANO» отеле, Казан ш., Уңъяк Болак ур., 49 нчы й. | Казан ш., Островский ур., 37/5 нче й. |
| 14. | «Казан» халыкара аэропорты» АҖ, Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге | Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге, аэропорт территориясе, 549 нчы бина |
| 15. | «Казан-1» тимер юл вокзалы, Казан ш., Вокзал яны мәйданы, 1 нче й. | Казан ш., Борхан Шәһиди ур., 1/15 нче й. |
| 16. | «Казан» елга порты, Казан ш., Девятаев ур., 1 нче й. | Казан шәһәре, Девятаев ур., 1 нче й. |